**Предмет:** Әйләнә-тирә дөнья.

**Класс:** 3 класс.


**Дәрес тибы:** Яңа белемнәр үзләштерү.



**"Су һәм аның үзлекләре" темасы буенча технологик карта.**



| **Тема** | "Су һәм аның үзлекләре". |
|---|---|
| **Максат** | Укучыларны суның үзлекләре һәм әһәмияте белән таныштыру;<br>Алардан табигатьттәге су әйләнешен күзаллауны формалаштыру;<br>Фронталь һәм индивидуаль эшләү культурасы тәрбияләү.<br>Универсаль уку гамәлләре формалаштыру:<br>*Шәхескә кагылышлы УУГ:*<br>Уку эшчәнлегенең уңышлар критериясе нигезендә үзбәяләү сәләте формалаштыру.<br>*Регулятив УУГ:*<br>Укытучы ярдәмендә дәреснең максатын билгели һәм формалаштыра белү; дәрестәге гамәлләр эзлеклелеген әйтү; төзелгән план буенча эшләү; үткәнгә карап бердәй бәяләү дәрәҗәсендә эш үтәлешенең дөреслеген бәяләү.<br>*Коммуникатив УУГ:*<br>Үзеңнең фикереңне телдән матур итеп әйтә белү; башкаларны ишетә һәм тыңлый белү;<br>*Танып-белү УУГ:*<br>Танып белү максатын билгеләү; кирәкле информация туплау;<br>Үткәндә өйрәнгәнне яңасыннан аера белү; дәреслектән, тормыш тәҗрибәңнән, дәрестә<br>Алган информациядән файдаланып сорауларга җавап бирү. |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр** | Предметлы: Суның үзлекләрен,табигатьттә су әйләнешен һәм аның әһәмиятен белү.<br>*Шәхескә кагылышы:* дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы.<br>*Метапредметлы:* Укытучы ярдәмендә дәреснең максатын билгели һәм формалаштыра<br>белү; дәрестәге гамәлләр эзлеклелеген әйтү; күмәк төзелгән план буенча эшләү; үткәнгә<br>карап бердәй бәяләү дәрәҗәсендә эш үтәлешенең дөреслеген бәяләү; ясалган хаталарны исәпкә алу һәм эшләрне бәяләүдән соң төзәтүләр кертү; үз фикереңне дөрес |

| | |
|---|---|
| | итеп әйтү; *(Регулятив УУ):*<br><br>Үзеңнең фикереңне телдән матур итеп әйтә белү; башкаларны ишетә һәм тыңлый белү;<br><br>мәктәптә аралашу кагыйдәләре турында сөйләшү һәм аны үтәү.*(Коммуникатив УУГ)*<br><br>Үзеңнең белем системасында ориентлаша белү; үткәндә өйрәнгәнне укытучы ярдәмендә яңасыннан аера белү; яңа белемнәр табу; дәреслектән, тормыш тәҗрибәңнән, дәрестә алган информациядән файдаланып сорауларга җавап бирү.<br><br>*(Танып-белү УУГ).* |
| **Төп төшенчәләр** | Суның үзлекләре, суның өч халәте. |
| **Предметара**<br><br>**Бәйләнешләр**<br><br>**Төп ресурслар** | Математика, әдәби уку.<br><br>УМК "Перспектива" Плешаков,Новицкая, Әйләнә-тирә дөнья.Беренче кисәк.<br><br>ИКТ: компьютер, проектор, дәрескә презентация. |
| **Өстәмә**<br><br>**ресурслар** | Тест биремнәре.<br><br>Уку эшчәнлеге адымнары.<br><br>Дәфтәр.<br><br>Үзбәя алгоритмы. |
| **Киңлекне оештыру** | Фронталь эш, индивидуаль эш, парларда эш. |

| Үткәрү технологиясе | Укучы эшчәнлеге | Укытучы эшчәнлеге | Планнаштырылган<br><br>Нәтиҗәләргә ирешү өчен укучыларга бирелгән биремнәр | Диагностик биремнәр |
|---|---|---|---|---|
| **I.Уку эшчәнлеген мотивлаштыру.**<br><br>Максат: | Шигырьне кабатларга;<br><br>Бер-берсенә елмаеп сәләм бирәләр,уңышлар | Үтәлергә тиешле таләпләргә туры китереп уку эшчәнлеген оештыру.<br><br>Укучының уку | 1)-Исәнмесез укучылар,кәефләрегез ничек ?<br><br>-Укучылар: | Ни өчен бу кагыйдәләр не һәркемгә үтәргә кирәк. |


| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| -укучыга уку эшчәнлегенә кереп китү өчен шартлар булдыру.<br><br>-уку эшчәнлеге адымнарын һәм дәреснең тибын ачыклау. | телиләр.<br><br>-үзләренең<br><br>кәефләрен билгелиләр. | эшчәнлегенә эчке ихтыяҗы тусын өчен шартлар тудыру,тематик рамка булдыру. | -Кояшлы иртә кебек.<br><br>-Укучылар ,кояшка карап елмаегыз,бер-берегезгә карап елмаегыз  һәм дәресне башлыйбыз.<br><br>-Нәрсә эшләдек?<br><br>(Дәрескә үзебезне көйләп куйдык). | <br><br>Слайд   1 |
| **II.Белемнәрне актуальләштерү**<br><br>**һәм сынау максатыннан үткәрелгән уку эшчәнлегендәге кыенлыкларга игътибарны юнәлтү.**<br><br>Дәреснең темасын ачу.Дәрескә максат кую.<br><br>Максат:<br><br>-укучыларның алган белемнәрен яңа материалны үзләштерүгә юнәлтү.<br><br>-алган белемнәрне кулланып үткән дәрескә нәтиҗә ясау. | Тест сорауларына җавап бирәләр.<br><br>Шаблон ярдәмендә,<br><br>укучылар бер-берсенекен тикшерәләр һәм нәтиҗә ясыйлар. | Кечкенә тест ярдәмендә өй эшен тикшерүне<br><br>оештыру. | 1)Һава турында табышмак әйтү.<br><br>-һава.<br><br>-Сез ничек уйлыйсыз,ни өчен бу табышмакны әйттем?<br><br>-Чөнки без алдагы дәрәстә һава турында өйрәндек.<br><br>2)-Әйдәгез кечкенә –тест ярдәмендә  үзебезнең белемнәребезне тикшереп алыйк әле.<br><br>-Укучылыр тест эшлиләр һәм бер-берсенекен  шаблон ярдәмендә тикшерәләр.<br><br>-Индикаторлар ярдәмендә үзбәя.<br><br>-Димәк укучылар ,нәрсәдән башка | Слайд  2<br><br><br><br>Слайд   3 |


| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | .<br><br>-Үзбәя. | Дәреснең темасын әйттерү. | яшәп булмый?<br><br>Нәтиҗә.Һавадан башка тереклек юк.<br><br>-Балалар яшәү өчен безгә тагын нәрсә кирәк?<br><br>-Укучылар ,карагыз әле,рәсемдә нәрсә күрәсез?<br><br>-Су рәсеме.<br><br>-Укучылар ,ә хәзер мин сезгә сораулар әйтәм,шул сораулар ярдәмендә сез дәреснең темасын ачыкларсыз.<br><br>4)Сораулар.<br><br>-Бөтен нәрсәдән дә көчле?<br><br>-Нәрсәне кулда тотып булмый?<br><br>-Тишекле чүмечтә нәрсә тормый?<br><br>_Су.<br><br>-Димәк бүгенге  дәреснең темасы- | <br><br>Слайд   4<br><br> |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | “Су”.<br><br>-Молодец! Дөрес!<br><br>(Тактага элү “Су”)<br><br>Нәтиҗә ясау:<br><br>Дәреслекнең темасын билгеләдек, ә хәзер максатын билгелик. | Слайд 5<br> |
| **III.Кыенлыктан чыгу проектын төзү.**<br><br>**Дәреснең максатын билгеләү.**<br><br>Максат:<br><br>-укучыларны оештыру<br><br>һәм яңа мәгълүмат алуга юнәлтү.<br><br>-укучылар дәреснең максатын әйтергә тиешләр. | Алдагы уку эшчәнлеге адымын атыйлар.<br><br>Алдагы этапны әйтәләр.<br><br>Дәрескә максат куялар.<br><br>Бергәләп план төзү.<br><br>Кыенлыктан чыгу чараларын атыйлар. | Алдагы уку эшчәнлеге адымын ачыклауны оештыру.<br><br>Дәрескә максат куюны оештыру.<br><br>Дәреснең планын төзүне оештыру.<br><br>Кыенлыктан<br><br>чыгу чараларын табуны оештыру. | -Нәрсә соң ул су?<br><br>- Сыеклык,без аны эчәбез.<br><br>-Әйе балалар,дөрес.<br><br>-Балалар әйтегез әле җир йөзендә су күп дип уйлыйсызмы?<br><br>-Әйе.<br><br>-Әйдәгез әле глобусны карыйк.<br><br>Космонавтлар җирне менә шулай күрәләр.<br><br>Әгәр глобусны тиз генә әйләндерсәк ул бертөсле зәңгәрсу күренә.<br><br>-Ни өчен? | Слайд 6<br> |


| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | -Чөнки анда сары,яшел,<br>көрән төсләргә кара –<br>ганда зәңгәрсу төс күбрәк.<br><br>-Ә,глобуста зәңгәрсу төс белән нәрсә сурәтләнгән?<br><br>-Безнең җир йөзендәге<br>океаннар,диңгезләр.<br><br>-Әйе укучылар,дәрес.<br><br>-Укучылар ,тыңлагыз әле табышмак әйтәм,аннан дәреснең максатын әйтерсез.<br><br>Табышмак әйтү. | |
| | Табышмакларның җавабын әйтү.. | | Исе юк , төсе юк<br>Аннан башка тормыш юк. | |
| | | | -Су. | Слайд 7 |
| | | | -Укучылар бу табышмакта су турында нәрсә әйтелә? |  |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | -Суның үзлеге һәм әһәмияте.<br><br>-Дөрес, молодцы.<br><br>-Балалар,без суның үзлекләре белән танышмы?<br><br>-Юк, таныш түгел.<br><br>-Укучылар,дәрескә нинди максат куябыз?<br><br>-Суның үзлекләрен өйрәнү.<br><br>-Дөрес! Бик яхшы!<br><br>-Әйдәгез тагын бер кат дөрес итеп дәреснең темасын һәм максатын әйтик.<br><br>-Дәреснең темасы: “Су һәм аның үзлекләре.“.<br><br>- Максаты: “Суның үзлекләрен һәм әһәмиятен өйрәнү.” | | Слайд 8<br><br><br> |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | -Укучылар без бүген дәрестә:<br><br>1)Суның өч халәте.<br><br>2)Суның нинди үзлекләре була?<br><br>3) Табигатьтә су әйләнеше ничек бара?<br><br>4)Кеше өчен суның әһәмияте?<br><br>-Шул сорауларга җавап эзләрбез.<br><br>-Безгә нәрсә ярдәм итә?<br><br>(Үзтәҗрибәм,дәреслек,укытучы). | Слайд 9<br><br> |
| | | | | |

<table>
<tr>
<td>IV. Төзелгән проектны реальлләштерү.<br>Яңа мәгълүматлар алу.<br><br>Эзләнү эше.<br><br>Максат:<br><br>-төзелгән проектны план буенча тормышка ашыру;<br><br>-кыенлык чыккан урынны һәм сәбәпне юкка чыгару;<br>-су турында яңа белемнәр туплау.<br><br>-эзләнү эше ярдәмендә суның үзлекләрен табу.</td>
<td>Алдагы эшчәнлек этабын укытучы ярдәмендә әйтәләр.<br><br>Укытучы ярдәмендә<br>төзелгән план нигезендә биремнәрне үтиләр.</td>
<td>Алдагы уку эшчәнлеге адымын ачыклауны оештыра.<br><br>Төзелгән план нигезендә биремнәрне үтәүне оештыра.</td>
<td>1.-Алдагы этап нинди?<br>(план буенча эшләү).<br><br>2. Диалог:<br><br>-Укучылар ничек уйлыйсыз, табигатьттә су нинди 3 халәттә очрый?<br><br>-Сыек, каты.<br><br>-Су кайчан каты була?<br><br>_Кыш көне,салкын вакытта.<br><br>-Температура 0 градуска тәшкәндә.<br><br>-Кайчан сыек була?<br><br>-Жылы вакытта.<br><br>-Дөрес,укучылар.<br><br>Табышмак әйтү.<br><br>-Укучылар су кайчан оча?<br><br>-Су парга әйләнгәндә.</td>
<td>Слайд 10<br>


<br>Слайд 11<br>



<br>Слайд 12<br>

<br>Слайд 13<br>

</td>
</tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Эзләнү эшен оештыра. | -Укучылар, су  бу очракта газсыман халәттә очрый.<br>(газсыман-суның парга әйләнүе).<br><br>-Укучылыр су нинди 3 халәттә очрый?<br><br>-Сыек,каты,газсыман.<br><br>Молодцы,укучылар.<br><br>Нәтиҗә ясау: табигатьттә су-сыек,каты,газсыман була.(томан,боз,су).<br><br>-Укучылар суның нинди үзлекләре була соң?<br><br>-Әйдәгез бу сорауга җавап табар өчен,үзебез эзләнү эше үткәрик.<br><br>-Моның өчен сезгә эзләнүчеләр булырга һәм лабораториядә тәжрибә үткәрергә туры килә.<br><br>**1.Тәжрибә**.Стакан белән су һәм кашык.<br><br>Нәтиҗә: су үтә күренмәле. | Слайд   14<br><br>Слайд   15<br><br><br>Слайд   16<br><br> |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | **2.Тәҗрибә.**Су белән стакан,төрле төстәге полоскалар.<br><br>Нәтиҗә: су төссез.<br><br>**3.Тәҗрибә.** Духи һәм стакан белән су.<br><br>Нәтиҗә: су иссез.<br><br>**4.Тәҗрибә.** Стакан белән су һәм шикәр комы.<br><br>Нәтиҗә: су эретүчән.<br><br>**5.Тәҗрибә.**Стакан белән су.<br><br>Нәтиҗә: су агучан(формасы юк).<br><br>-Әйдәгез укучылар,нәтиҗә ясыйк ,су нинди үзлекләргә ия?<br><br>**Нәтиҗә:** иссез,төссез,үтәкүренмәле,эретүчән,агучан матдә.<br><br>-Үзбәя. | Слайд 17<br><br><br>Слайд 18-19 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Физминутка** | | | | <br><br><br> |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **V. Беренчел ныгту.**<br><br>Максат:<br><br>-укучыларның аңлап эшләү эшчәнлекләрен оештыру;<br><br>-дәреслек буенча алган белемнәрне ныгыту. | Алдагы эшчәнлек этабын укытучы ярдәмендә әйтәләр.<br><br>Укытучы ярдәмендә<br><br>төзелгән план нигезендә биремнәрне үтиләр. | Алдагы уку эшчәнлеге адымын ачыклауны оештыра.<br><br>Дәреслектән уку.<br><br>Аңлата бару.<br><br>1 укучы сөйли. | 3.- Балалар,су кайларда саклана?<br><br>-Елгада,чишмәдә,күлдә,океанда.<br><br>-Дөрес, укучылар.<br><br>-Су океаннарда, диңгезләрдә ,чишмәләрдә була.<br><br>-Балалар ,су безнең җир шарының 3\4  өлешен тәшкил итә.<br><br>-Су бөтен җирдә- һавада да (пар,болытлар) ,җирдә дә ( чишмәләр) бар.<br><br>-Укучылар безнең якларда нинди чишмәләр бар?<br><br>Көрин чишмәсе, хуҗалар тавы чишмәсе.<br><br>Әлфинә сөйли..<br><br>“Көрин “ чишмәсе турында.<br><br>-Барлык тере организмнарда да су бар.(яфракта,үлән тамырларында).<br><br>-Хайван организмның яртысы диярлек судан тора. | Слайд  20<br><br><br>Слайд  21<br><br><br>Слайд  22<br> |


| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | -Кеше организмының да  70%  ы судан тора.3 көннән артык кеше сусыз яши алмый. | Слай д   23<br><br> |
| **VI. Эталон буенча мөстәкыйль эшләү.**<br><br>Максат: | Дәфтәрләрдә мөстәкыйль эшлиләр. | Алдагы уку эшчәнлеге адымын ачыклауны оешты | _Балалар ,үзегезнең организмыгызда ничә килограмм су барлыгын белергә телисезме?<br><br>-Әйе,телибез. | |


| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| -яңа белемнәрне кулланып мөстәкыйль эшләү.<br><br>-үзтикшерү һәм үзбәяләүне оештыру. | Үзбәя куялар.<br><br>Үзара тикшерәләр. | | -Әйдәгез дәфтәрләрдә мөстәкыйль эш эшләп алыйк.<br><br>-Үзегезнең гәүдә авырлыгыгызны 3 кә бүлегез һәм 2 гә тапкырлагыз.<br><br>-Үзара тикшерегез.<br><br>-Үзбәя кую.<br><br>-Укучылар,дәреслекнең 64 нче битендәге рәсемне күзәтегез әле.<br><br>-Табигатьттә су әйләнеше ничек бара?<br><br>-Кем аңлатып бирер?<br><br>-Дөрес,балалар.<br><br>Нәтиҗә ясау: су пар рәвешендә өскә күтәрелә,пар суына һәм болыт ясала.Ул болыт яңгыр яки кар булып кире җиргә ява. | Слайд 24<br><br><br><br>Слайд 25<br><br> |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **VII.Кабатлау һәм ныгыту.**<br><br>Максат:<br><br>-алган белемнәрне тормышта куллана белү.<br><br>-алган белемнәргә таянып үз фикерләрен әйтү. | | 1 укучы шигырь сөйли. | Алдагы этап нинди ?<br><br>(кабатлау һәм ныгыту).<br><br>Укучылар кеше өчен суның нинди әһәмияте бар?<br><br>-Су ярдәмендә нәрсәләр эшлибез?<br><br>-Нәргизәнең шигырен тыңлап китик әле,аннан җавапларыбызны әйтербәз.<br><br>-Юыну ,эчү өчен,бакчаларга сибү өчен.<br><br>-Укучылар су  безгә электр тогын табарга ярдәм итә,йөк ташу өчен юл хезмәтен үти.<br><br>_Балалар диңгезләрдә океаннардә су эчәргә яраклымы?<br><br>-Ни  өчен? | Слайд   26<br><br><br> |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 укучы шигырь сөйли. | -Чөнки анда су тозлы.<br><br>-Балалар, ә кешегә эчәр өчен нинди су кирәк?<br><br>-Чиста су.<br><br>Нәргизә шигырь сөйли.<br><br>“Чиста су,йөгерек су”.<br><br>-Ә чиста сулар әзәйгәннән -әзәя бара.<br><br>-Ни өчен дип уйлыйсыз?<br><br>-Чөнки кешеләр суны пычраталар,кирәкмәгәнгә дә су агызалар.<br><br>-Ә ничек пычраталар соң?<br><br>-Чүп-чар ташлыйлар,завод-фабрикалардан пычрак сулар агызалар.<br><br>-Балалар дәреслекнең 63 битеннән суның әһәмияте турында укып китик әле һәм нәтиҗә ясыйк.<br><br>-Укучылардан укыту. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | -Димәк суны нишләргә кирәк?<br><br>Нәтиҗә ясау: суны сакларга,чишмәләрне чистартып торырга кирәк ,су иң кирәкле матдә.<br><br>- | Слайд 27<br><br> |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **VIII. Дәрестә уку эшчәнлеген рефлексияләү.**<br><br>Максат:<br><br>-укучыларның эшенә анализ ясау,бәяләү.<br><br>-алган белемнәре буенча үз фикерләрен әйтү,аны тормышта кулланырга әзер булу. | Укучылардан сөйләтү.<br><br>Укучылар индикаторлар ярдәмендә күрсәтәләр. | Укучыларның эшчәнлеген бәяләү.<br><br>Яшел төс-дәрес ошаса һәм бик актив катнашса. | -Сез дәрестә нинди матдә белән эшләдегез?<br><br>-Нинди ачышлар ясадыгыз?<br><br>Максатка ирештекме?<br><br>Мин бүген дәрестә:<br><br>-белдем<br><br>-искә төшердем<br><br>-гаҗәпләндем<br><br>-миңа ошады<br><br>-ачыш ясадым<br><br>(Укучылырның җаваплары)<br><br>-Молодцы,укучылыр. | Слайд 28<br><br><br>Слайд 29 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Сары төс-дәрес ошаса,тик укытучы ярдәм итсә.<br><br>Кызыл төс-дәрес ошамаса,бернәрсәдә аңламаса. | -Ә хәзер сигнал карточкалар ярдәмендә дәрескә бәя бирик.<br><br>-Тиешле карточкаларны күтәрүегезне сорыйм.<br><br>-Яхшы! Сез дәрестә бик актив булдыгыз.<br><br>Укучыларга билгеләр кую.<br><br>-Үзбәя.<br><br>-Укучыларга билгеләр кую. |  |
| **VIII.Өй эше турында мәгълүмат.**<br><br>Максат:<br><br>-балаларга өй эшен әйтү һәм эшләү методларын аңлату.<br><br>-өй эшен сайлап | Укучылар өй эшен сайлап алалар. | | Мин сезгә төрле дәрәҗәдәге биремнәр бирәм.<br><br>-Шуларның берсен генә сайлап аласыз.<br><br>1 бирем. Аңлатмалы сүзлектән су сүзенең аңлатмасын язып килергә.<br><br>“Су-ул... | Слайд 30<br> |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| алырга һәм дөрес итеп эшләргә. | | | 2 бирем. Су турында мәкальләр һәм әйтемнәр язып килергә. | Слайд 31   |